Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

«Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура
һәм сәнгать музей-тыюлыгы

Ибраһим Идрис

# Тәрбияле ата яки тормыш дәресе

«Тәрбияле ата» ике сүздән генә гыйбарәт булса да,
эченә бик күп нәрсәләрне алып һәм бу мәсьәләдә матбугат
галәмендә бер китап та күренмәгәнлектән, йөздән берсен генә
булса да язып, бастырып нәшер итүне муафыйк күрдем.

*Ата икәнсең – ата булырга тырыш,*
*Урыны белән балаларыңны орыш.*
*Тәрбиядә һич киметмә атаңны,*
*Шәфкатьле һәм иң сөекле анаңны.*
*Сәбәп булдылар синең килүеңә*
*Һәм тереклек һәм тормыш белүеңә.*
*Тырыш аларның догасын алырга*
*Һәм үзеңне туры юлга салырга.*

Казан – 2019

УДК 130.2:28
ББК 74.9р
И 28

**Китапны басмага әзерләүчеләр**:
филология фәннәре кандидаты *Айдар Гайнетдинов*,
Ислам мәдәнияте музее мөдире *Илнур Низамиев*

И 28 ***Идрис И.*** **Тәрбияле ата яки тормыш дәресе** / Басмага әзерләүчеләр *А. Гайнетдинов, И. Низамиев*. – Казан: Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. – 32 б.

ISBN 978-5-94981-326-3

«Тормыш дәресе яки тәрбияле ата» – шагыйрь, педагог, нәшир, сәүдәгәр Ибраһим Идриснең тәрбия нигезләренә багышланган хезмәте. Анда аның кыйммәтле фикерләре, киңкырлы карашлары, акыллы киңәшләре чагылыш тапкан. Китап мөгаллимнәргә, тәрбиячеләргә, дин әһелләренә, гомумән, татар халкының педагогик мирасы белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

© Гайнетдинов А., Низамиев И., 2019
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019
© «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура
һәм сәнгать музей-тыюлыгы, 2019

# *КЕРЕШ*

*Шагыйрь, педагог, нәшир, сәүдәгәр Ибраһим Сөләйман улы Идрис 1857 елның 11 маенда хәзерге Татарстан Республикасы Арча районы Наласа авылында дөньяга килгән. 1897 елда ул Казанга күченгән һәм көнкүреш товарлар, китаплар белән сату иткән. И. Идрис 1907 елда дин галиме Галимҗан Баруди белән берлектә сәүдә йорты оештырып, китаплар белән сату иткән. 1908 елда исә үзенең «Милләт» дип аталган нәшриятын ачкан. Анда 1917 елга кадәр 1,3 миллионнан артык данә белән 256 китап чыккан. Бу китаплар дин, әдәбият, тарих, медицина, гарәп фәлсәфәсе һәм башка темаларга багышланган. Алар белән беррәттән календарьлар, каталоглар да чыккан.*

*И. Идрис җәдидчелеккә, педагогикага караган мәсьәләләр белән нык кызыксынган. Иҗатының беренче җимешләренең берсе буларак, 1900 елда М. Чиркова варислары басмаханәсендә И. Идриснең «Тәрбияле ата» исемле хезмәте дөнья күргән. Шунысын әйтергә кирәк: китап тышлыгында ул үз исемен куймаган, авторы ике «әлиф» белән, ягъни «ا.ا.» (И.И.)инициаллары рәвешендә күрсәтелгән, шулай да «И. Идрисовның хәраҗаты илән» дип, ягъни хезмәтнең И. Идрисов хисабына басылганлыгы язылган[1]. Үгет-нәсыйхәт формасында төзелгән әлеге китапта үрнәк ата булу өчен иң беренче чиратта игътибар ителергә тиешле мәсьәләләр кыскача аңлатылган.*

---

[1] Тәрбияле ата. – Казан: М. Чиркова варислары басмаханәсе, 1900 (1318). – 16 б.

*1905 елда И.Н. Харитонов басмаханәсендә бу китап байтак тулыландырылып һәм өлешчә үзгәртелеп, «Тәрбияле ата яки кыйраәт төрки» исеме белән кабат басылып чыккан, тик анда да авторы күрсәтелмәгән, бәлки «И. Идрисовның акчасына басылды» дип кенә язылган[2]. Өченче һәм дүртенче басмаларында анысы да язылмаган[3]. Шунысын да әйтергә кирәк: дүртенчесе «Тәрбияле ата яки тормыш дәресе» дип аталган һәм ул 1900 елгы басмасыннан күләмлерәк һәм шактый аерыла.*

*И. Идрис педагог кына түгел, шагыйрь буларак та билгеле. Аның 1914 елда «Кыз балаларга нәсыйхәт» дип аталган шигырьләр җыентыгы дөнья күргән. Анда «Уку», «Ислам дине», «Мәдех», «Пакьлек бәяне», «Сәламәтлек», «Авыруга сабырлык», «Ашамак бәяне» һ.б. әсәрләре урын алган[4]. И. Идрис үз китапларының титул битендә шигъри юллар язып куюны гадәт иткән.*

*И. Идрис 1944 елның 31 мартында вафат булып, Казанның Яңа татар бистәсе зиратында җирләнгән. Өстән караганда өчпочмак формасында ясалган кабер ташында түбәндәге сүзләр язылган:*

*Беренче ягы (уеп язылган):*

*1) «Әл-хүкмү лилләәһи Тәгааләә*

*2) Милләт*

---

[2] Тәрбияле ата яки кыйраәт төрки. – Казан: И.Н. Харитонов басмаханәсе, 1905. – 32 б.

[3] Тәрбияле ата. – Казан: «Милләт» басмаханәсе, 1908. – 3 нче басма. – 19 б.; Тәрбияле ата яки тормыш дәресе. – Казан: «Милләт» нәшрияты, 1915. – 4 нче басма. – 24 б.

[4] Идрис И. Кыз балаларга нәсыйхәт. – Казан: «Милләт» басмаханәсе, 1914. – 16 б.

*3) көтебханәсенең*

*4) сахиб вә нәшире*

*5) Ибраһим*

*6) бине Сөләйман*

*7) Идрис*

*8) Наласа авылында*

*9) туган*

*10) 87 йәшендә вафат*

*11) 31 март 1944 сәнәдә*

*12) рахимәһүллааһү Тәгааләә*

*13) рахмәтән вәәсигаһ».*

*Икенче ягы (уеп язылган):*

*1) «Йөрдем атсыз талмады айакларым*

*2) эшләдем эш тынмады бармакларым*

*3) мәхрүм итмәңез догадан*

*4) дустларым тармакларым*

*5) Ибраһим Идрис».*

*Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе*

*Беренче ягы:*

*1) «Хөкем Аллаһ Тәгаләдә.*

*2) «Милләт»*

*3) китапханәсенең*

*4) иясе һәм нәшире*

*5) Ибраһим*

*6) бине Сөләйман*

*7) Идрис*

*8) (Наласа авылында*

*9) туган)*

*10) 87 яшендә 1944*

*11) елның 31 мартында вафат.*

*12) Аллаһ Тәгалә аны киң*

*13) рәхмәте белән рәхим кылсын».*

*Икенче ягы:*

*1) «Йөрдем атсыз – талмады аякларым,*

*2) Эшләдем эш – тынмады бармакларым.*

*3) Мәхрүм итмәгез догадан*

*4) Дусларым, тармакларым.*

*5) Ибраһим Идрис».*

*Күргәнебезчә, И. Идриснең кабер ташында да үзенең шигыре язылган. «Йөрдем атсыз – талмады аякларым, эшләдем эш – тынмады бармакларым» сүзләре әлеге олы шәхеснең тормыш юлын, эшчәнлеген, иҗатын тулысынча тасвирллый диярлек.*

*Күренекле галим Ризаэтдин Фәхретдиннең «Тәрбиядән яраладыр тәрбия» дигән фикере барчабызга да билгеле. Матур гаилә кора алырлык, дөрес мөнәсәбәтләр алып барырлык, үз балаларына тиешле әдәп-әхлак биреп, тормышка ак юл ачарлык ата-ана тәрбияләү – җәмгыятьнең зур бер бурычы. Әтисенең яхшы үрнәген күреп үскән һәрбер адәм үзүзен дә, шул ук вакытта, җәмгыятьне дә тәрбияли ала. Менә бу тәрбиядә уңышка ирешергә омтылучылар өчен игътибарыгызга тәкъдим ителә торган китап зур бер ярдәмче була ала.*

*Бүген дә рухи үсеш – көн үзәгендә тора торган мәсьәләләрнең берсе. Ибраһим Идриснең «Тәрбияле ата яки тормыш дәресе» хезмәте мәгърифәтче галим Риза казый язган тәрбияви китаплар сериясенә бик охшаш. Ул XX гасыр ба-*

*шында, ягъни медицина, психология, педагогика кебек фәннәр үсеш алган чорда дөнья күргән. Ул вакытта гасырлар буе яшәп килгән гореф-гадәтләрнең күбесенә фәнни дәлилләр табылган, кайбер начар гадәтләр тәнкыйтькә дучар булган. Нәкъ шул дәвердә И. Идрис фәнни гыйлем, дини йолалар, гореф-гадәтләрне бергә кушып, тәрбия вакытында файдалы булырлык фикерләрне генә алып, аларны кечкенә китапка туплаган. Аны ул яшь әтиләргә юллап, балаларына гүзәл үрнәк күрсәтү өчен иң дөрес форматны, ягъни гади тел белән файдалы киңәшләр бирү юлын сайлаган.*

*«Тәрбияле ата яки тормыш дәресе» китабы хатын сайлау, тормышны башлап җибәргәндә хәләл җефет белән мөнәсәбәтләрне төзеп җибәрү кебек темалар белән ачылып киткән. Тәрбиядә пакълек, бала сәламәтлеге мәсьәләсенә аерым игътибар бирелгән. Автор бала тәрбияләүдә булган төрле психологик алымнарны күрсәткән, дини һәм милли тәрбиягә нык игътибар биргән. Хезмәт ахырында И. Идриснең ике шигыре китерелгән.*

*1915 елда басылган «Тәрбияле ата яки тормыш дәресе» әсәрен без, гарәп графикасыннан кириллицага күчереп, хәзерге телгә яраклаштырып, тәкъдим итәргә булдык. Кадерле укучылар әлеге китаптан файда алырлар, тәрбия өлкәсендә гыйлем тупларлар, дигән теләктә калабыз.*

## Бисмилләһир-рахмәнир-рахим

Бер егет өйләнмәкче булса, бу нияттә булу тиешле: (хатын-кызларның ризыгы күбрәк ирләр аркылы килүенә нигезләнеп) Аллаһ Тәгаләнең бер бәндәсен үзенә никахлап алып, аны тәрбияләү, ягъни ашату, эчертү киендерү һәм аннан килгән балаларны тәрбияләп үстерү, укыту, кәсеп-һөнәр өйрәтү, угыл булса, өйләндереп, кыз булса, тәрбияләп, кияүгә бирү ниятендә булу тиешле.

Моның киресенчә, ничек тә бай җирдән алып, аның аркасында рәхәт торырмын, дип, акчалы надан кыз яки яше үзеннән югары, күренеше үзеннән түбән, үзенә бер дә тиң булмаган акчалы хатын алып, аның акчасы белән тору ниятендә булу – Ходага тәвәккәлсезлек, тәрбияле ата исемен күтәрәчәк булган егетләргә тиешле эш түгел. Бәлки мондый сакалсыз ирләргә мыеклы хатын, икенче төрле әйткәндә, кол булу – егет булган кешегә гарьлек. Чөнки акчалы хатын иренә чын мәгънәсе белән хатын булып яши алмый. Адәм баласының әгъзалары сәламәт булса – үзе акча. Әгъзаларын тиешле хезмәткә куша белсә, яманлыктан сакланса, чыгымын килгән кадәр тотса, ризыгы, шөбһәсез, җитешәчәк.

Бер егет югарыдагы ният белән өйләнсә, йорт эченең тынычлыгы өчен беренче нәсыйхәт – бу: җәмәгате үз йортына килеп тора башлагач, ул хатынына табигатенең ни рәвешле булып, кайсы эшләрне яратып, кайсы эшләрне яратмавын яхшы аңлатырга тиеш, чөнки икесенең арасында камил төзеклек булсын өчен бер сүздә һәм бер фикердә булулары тиешле. Соңра ата-анасына түбәнчелекле булырга, мөмкин кадәр йорт эченең хезмәтен үтәргә бурычлы икәнен

аңлатырга кирәк. Бу нәсыйхәтне ирләре бирмәсә яки ирләре биреп тә, килен үзе үтәмәсә, ул йорт эчендә төзеклек дәвам итмәячәк. Аларны гадәт рәвешенчә «әткәй», «әнкәй» исеме белән дәшәргә гадәтләндерергә тиеш, алар да киленнәреннән хуш күңелле булсыннар өчен. Аннан соң йорт гадәтләрен йортта булган ашау-эчү, аш әзерләү, ризыкларны барлау кебек эшләрне тәмам кат-кат өйрәтү тиешле; мин ир дигәч тә, төшенеп җитмәгән ят җиргә килгән бер кызны тиз генә орыша башламаска тиеш. Янә өйдән рөхсәтсез чыкмаска һәм тиешсез кешене өйгә кертмәскә – башта бик яхшы аңлатырга тиеш. Әгәр кемнәргә барырга ярый, кемнәр аңа килергә ярый, кемнәрдән тел һәм кемнәрдән йөз яшерергә тиеш – һәркайсын башта аңлатырга кирәк. Йортбозгыч хатыннар белән утырышып, аның әхлагы бозылмасын. Ирләр үзләре ирекле, хатынга караганда белүче була торып, алдагы барышның кайсылары ярап, кайсылары ярамаячак икәнен әйткән булмаса, хатынының бер ярамаган җирен күрү белән орышу һәм кыйнау зур хаксызлык була. Мәсәлән, бер ир үзенең хатынын һәрбер ирләр белән күрешергә һәм бер мәҗлестә утырырга ирек куйса, шул ук хатынының башка бер ир белән дуслыклары үсеп китеп, шәригать ягыннан бер тиешсез эш беленгән сурәттә, хатынны мы орышырга яки иренме кыйнарга тиешле – моны укучылар үзләре фикер итәрләр. Бәлки беренче мәртәбәсендә, алай ярамый, бу эшне миңа икенче мәртәбә күрсәтмә, дип нәсыйхәт бирергә тиеш. Икенче мәртәбә беленсә, караңгы чырай күрсәтү тиешле, сүзләр белән орышып, икенче [вакытта] янә шулай эшләсә, җәза бирәчәген белдереп, ярамаган эшләрен куйдыруга тырышырга тиеш. Бу кадәр орыш һәм шелтәләүләр балалар ал-

дында булу һич тә ярамый. Алар андый тормышны күреп үсмәсеннәр.

Тәрбиясез ирләрнең гадәтенә ияреп, хатынын кыйнамаска тиеш. Аеруча беренче мәртәбә сукмаска бик тырышырга кирәк. Бер суга башласаң, кулың һаман сугарга җитешер, үзең сизми дә калырсың. Соңра уйлап карасаң, орышып үтә торган урынга кул белән җәза биреп, үзең белән бергә гомер итә башлаган җәмәгатеңә сугып, арада булган мәхәббәтнең дәрәҗәсен киметкәнеңне уйлап, үкенерсең, тормышның ләззәтсез үтүен, йортның бәрәкәте китүен уйласаң, әллә ни кадәр зарар иткән булырсың.

## Балаларның тәрбиясе хакында

Тәрбияле аталар балаларга сабый вакытта һәрдаим шәфкать күзләре белән карап, аларга ашау-эчү кебек хәҗәтләрен хәләлдән әзерләп китерерләр. «Миңа җәфа булдыгыз, имгәкләр» кебек сүзләр белән зарлану юлында сүз сөйләмәсләр. Бәлки, болар Ходаның бәндәсе булуына сәбәпче мин булдым, тәрбиясе миңа фарыз һәм тиеш, дип белеп, кәсебе аркылы Аллаһ биргән нигъмәтне сөенә-сөенә алып кайтып, тәрбияләрләр, шуның белән Аллаһтан әҗерен өмет итәрләр. Шул ният белән тәрбияләсәләр, әҗере, шөбһәсез, булачак, иншалла.

Балага азрак акыл кереп, белә башлагач, ата-анасы бер сүздә булып, балага әдәп һәм күркәм холык өйрәтергә тырышырлар. Мәсәлән, баланың бер гаебе булып, атасы орышканда, анасы аркылы төшмәс, бәлки анасы янә нәсыйхәт бирер: «Менә, балам, икенче мәртәбә алай эшләмә, атаң сине

тиешле урынга орышты», – дип, үз ягыннан янә салкынлык күрсәтер. Әгәр атасы орышканда, анасы яки анасы орышканда, атасы якласалар, бала бердән бергә бозылыр, төзәлүе дә өметсез булыр. Тәрбияле аталар балаларына бер генә дә ялган сөйләүне ихтыяр итмәсләр. Баштал балаларына әйтерләр: «Бер нәрсәне без күрмәгәндә ватсагыз яки бер нәрсәне ашасагыз, соңра безгә беленеп, сораганда, «Мин ватмадым, мин ашамадым», – дип ялганламагыз, дөресен әйтегез, дөресен әйтсәгез, сезгә шәфкатем булыр, гаебегезне кичерермен. Әгәр котылып калмакчы булып, ялганласагыз, ул ялган миңа кайчан да [булса] беленер. Ул вакытта минем җәзам сезгә бик каты булыр», – дип, балаларның колакларына кат-кат аңлатырлар. Инде баланың бер гаебе беленсә, башта: «Балам, зинһар, ялганлама, ялган хәрам, дөресен сөйлә», – дип әйтер. Соңра баладан куркытмый гына, бу эш ничек булды, дип сорар. Ул вакытта бала, шаять, дөресен әйтер. Дөресен әйтсә, югарыдагы вәгъдә буенча баланы кыйнамас, бәлки балага: «Бу юлга гаебеңне кичердем, икенче [юлы] алай итмә», – дип әйтер. Баладан: «Әти, бу юлга гафу ит, икенче мәртәбә алай эшләмәм», – дип әйттереп, вәгъдә алыр, шарт иттерер. Бер бала кечкенә вакытында ялганлап өйрәнсә, үлгәнче ул гадәтен ташлый алмас.

## Балаларның паклегенә күз салу

Тәрбияле аталар балаларны пакь йөртү турысында аналарга гына ышанып бетмәсләр, бит-кулларын юмыйча, маңкасын һәм авыз читләрен сөртмичә, керле күлмәк-ыштан киеп йөрүдән тыярлар. Кул һәм аяк тырнакларын җиткән саен

кисү белән аналарына яки караучыларына әмер итәрләр. Бер баланың тырнагы җиткән, күлмәк-ыштаны керле һәм бетле булса, «Бу баланың ата-анасы тәрбиясез икән», дип хөкем итәргә мөмкин булыр. Ир бала булса, алтын йөзек, ефәк нәрсәдән хәрам киемнәр кидертмәсләр. Бәлки бу заманда милләтебезгә хас булган, читтән караганда, бу ислам баласы икән, дип уйларлык кием киендерерләр. Аларга сурәтле булган уенчыклар алып бирмәсләр. Өй, тегермән, көймә, чана кебек тормышта тотыла торган нәрсәләрнең сурәтле булмаган уенчыкларын алып биреп, балаларның зиһенен ачарга тырышырлар. Тәрбияле аталар балалары ун яшенә җитсә, намазларын һәрвакытта күздән үткәреп, укытырга тырышырлар. Сабый вакытта мәчеткә йөртеп, әдәпсез-тәрбиясез балалар белән мәчеттә намазны уйный-уйный укытып өйрәтмәсләр. Бала вакытта шаярып уку зурайгач ихлассыз укуга сәбәп булыр. Үзе базарга кәсебенә чыкса, җәмәгатенә: «Балалар йокыдан торгач, намазларын укысыннар», – дип әйтеп чыгар. Кич кайткач, җәмәгатеннән: «Балалар һәр намазларын укыдылармы?» – дип сорар. Әгәр укымаган булсалар, калган намазларын, үз күзе белән карап, укытыр. Шул рәвешле тәрбияләсәләр, балаларга намаз уку яшь вакыттан гадәт булып, намазларын калдырмый торган һәм ихласлык белән укый торган булырлар. Бу – тәҗрибә белән беленгән бер эш.

## Тәрбияле аталар

Үсүдә булган балаларының якты йөзле, тапкыр сүзле, шат күңелле, таза бәдәнле булып үсүенә чын мәгнәсе белән тырышырлар. Аллаһ Тәгалә ничек яратса, шулай үсәр, дип,

үзебезнең тәрбиядәге кимчелегебездән килгән черек сыйфат-ны Аллаһка сылтап, Аллаһ шулай яраткандыр, дип әйтүебез – зур ваемсызлык. Күрәсез, башка милләт (рус) балаларын: битләре әнис алмасы шикелле, күзләре якут кисәге шикелле, тешләре ак сәдәп шикелле, калын җилкәле, юан балтырлы, йөз күренеше әрчегән шалкан кебек балалар.

Болар белән чагыштырып караганда, безнең милләт балаларының битләре керле, йөзләре тонык, тешләре сары, яшенә караганда, гәүдәсе кечкенә һәм ябык, бик күбесе шад-ра, сукыр һәм камыт аяклы, һәркайсының диярлек күңеле төшенке, йөзләрендә бер кайгы галәмәте күренә. Кеше янына килсәләр, бер дә сөйләшә алмыйлар. Менә балаларның бу кыяфәттә булуларына ата-аналары сәбәпче. Бер ата да, балам ямьсез булса иде, дип әйтмәсә дә, моның ямьле күренешле итеп үстерүнең рәтен белми. Сәбәпләрен түбәндә язабыз.

Битләре керле дидек. Моның сәбәбе – балага иртә-кич яхшылап сабын белән юынырга өйрәтмәгәннән килә.

Йөзләре тонык дидек. Моның сәбәбе – бу балага теләгәнчә уйнарга, шатланырга, көләргә ирек бирелмәгән, бу бала һаман орыш һәм шелтә астында үскән, балалыгы белән, бер гаебе булса, мине кыйныйлар, дип, коты очып торганнан килә.

Тешләре сары дидек. Моның сәбәбе – аштан соң тешне чистартмаганнан һәм юмаганнан килә. Мондый тешләр сыз-лаучан да була.

Гәүдәсе кечкенә, ябык дидек. Моның берничә төрле сәбәбе бар. Беренчесе – безнең аналарыбыз баланы бик кы-сып бәйлиләр һәм ничә айларга чаклы бәйлиләр, биләү исә өстенә тигез ябылмый калып, бала тумасын өчен һәм кулы

белән бит-күзен тырнамасын өчен генә булганлыктан, буш кына бәйләргә тиешле иде.

Ябык булуының сәбәбе – балага имчәкне вакытында гына бирми, көндез – вакыты килгәндә, төнлә – төне буенча имезә. Аның өстенә, баланы бик аз коендыра, кимендә көненә бер коендырырга кирәк иде. Аны да пакь су белән коендырмый. Һәркем белә, яшь баланың асты сидекле һәм нәҗесле була, башта баланы җылы су белән юып, арындырырга кирәк иде. Ул аны, коендырырга дип әзерләнгән суга, шул килеш сала. Ул гына да җитмәгән төсле, элекке биләвеннән чишкән нәҗесле чүпрәген, салдырган нәҗесле күлмәген баланың башы астына сала да, ару суны ике төрле нәҗес белән тәмам пычратып, шул су белән баланың битен, күзен юып, өстен бер кат комган суы йөгерткән булып, арындырдым, дип, чыгарып, янә биләүгә салып, кысып бәйләп яткыра. Пакь су белән юылмаганлыктан, баланың тәне кычытып, бала сыкрый, тынычсызлана. Шуны ишетүе белән, анасы алып, янә имчәк биреп, юатырга мәҗбүр була. Менә бу хәлне безнең татар хатыныннан сораганда, бер ана да әйтә алмас, тик: «Шулай итәбез шул», – диярләр. Пакь су белән юып, сабын [белән] керен бетереп, яткырса, бала тоташтан дүрт-биш сәгать йоклар иде. Аларның күбесе моннан гафил.

Шадра, сукыр була дидек. Моның сәбәбе: бала туып бер ара торгач та, фәнни чәчәк салдырырга кирәк иде. Аңа барып салдырту кайда, авылында туры килсә дә, качырып калдыра.

Камыт аяклы була дидек. Балага алты ай тулганчы, имчәк сөтеннән башка бер ризык бирмәскә кирәк иде. Алар суырып ятсын, дип, боламык, манный боткасы, баерак булганнары майлы ит калҗасы суырталар. Шушының белән ба-

лада сөяк авыруы була, ягъни сөяк кирәгенчә катмый, йомшак килеш тора. Бу бала дәрт белән аягына бераз басып йөри башлаганнан соң, аягына көч килеп, балтыр сөяге тышка таба яки эчкә таба кәкрәя башлый. Моннан соң бала аягына басмас булып, фәкать күтенә генә утыра торган була, ул вакытта җилкәсе яки күкрәге чыга. Менә моннан соң әлеге бала үстерүче аналарыбыз: «Баламның аягы йөри башлаган иде, ләкин салкын тиде», – дип исем бирәләр. Мондый бала дүрт яшенә кадәр аягына басып йөри алмый.

Дүрт яшь тулгач, ничек тә йөри башласа да, бала аягы кәкре, арка һәм күкрәге чыгып үсә.

Кеше янына килсә, сөйләшә алмый, күңеле төшенке була дидек. Баланың ата-анадан курку мәртәбәсенә җитешмәгән чагы була, шул вакытында һәр сүзне сөйләшмәкче була, бу – үз кеше, дип белми, бу – кунак, дип белми, һәркем катында сөйли. Әнә шул вакытта баланың мәрхәмәтле ата-анасы: «Бар, чык, абыйның пәкесе бар, колагыңны кисәр, күп сөйләшмә, оят була», – дип, баланы орышып, куып җибәрә. Баланың бу нигъмәте дә юкка чыга. Зуррак булгач та, аңа сөйләргә ихтыяр бирми, «Син олылар сөйләшкәнне тыңлап тор, зур булгач, сөйләшерсең», – ди. Шул сәбәпле, бала кеше каршысында сөйләшә алмый торган була.

Йөзендә кайгы галәмәте була дидек. Моның сәбәбе: ата-анасы арасында чын мәгънәсе белән мәхәббәтле тормыш булмаган була. Бу да берничә сәбәптән килә. Беренчесе – күп ирләр хатыннарга түбән карап, каты кулланулары сәбәпле, иреннән куркып торган хатынның һәр сәгать, һәр минутта йөзе караңгы була. Икенчесе – бала анасының төсендә һәрдаим караңгылык күреп, ул да шат булмый. Өченчесе –

егет үз теләгәнен алмаган, кыз да үзенә тиң булмаган кешегә көчләнеп кушылган булсалар, болар һәр ике хәлдә тәмле тормыштан ерак төшкән булалар (моның тәфсиле кыз бирү фасылында язылыр) Мәхәббәтле, ләззәтле тормыш булмадымы, ир бер яктан, хатын икенче яктан, балалар өченче яктан кайгы эчендә булалар. Бу кайгылы тормыш бер атналык яки бер айлык кына түгел, бәлки бөтен гомерләре шулай үтә. Көндезләре кайгылы үткән төсле, кичләре дә шулай була. Болардан яралачак балага бу табигать бик ныкъ тәэсир итә. Бер алма агачына шомырт агачы ашласаң, юкә алмасы булып үсми, монысы мәгълүм.

## Балаларны сабакка бирү

Тәрбияле аталарның балаларына сабак башлату һәм йөртү рәвеше.

Тәрбияле аталар балаларына: «Сабакка бар», – дип кенә бер балага ияртеп җибәрмәсләр, бәлки мәдрәсәнең мөдәррисенә яки мөдәррис тарафыннан куелган хәлфәгә үзе алып барып: «Әфәндем, сезгә баламны китергән идем, һәрничек кабул итеп үзегезгә яхшы булган рәвештә сабак укытсагыз ла! Бала вакытын буш үткәрмәсә иде, сабагында тырышуына яки ялкауланауына күз сала торсагыз ла, дәресендә ялкаулык кылса яки килми калса, миңа белдертсәгез лә», – дип үтенерләр. Кулыннан килгән кадәр сәдакаларын бирерләр һәм борынгы әбиләрнең сүзенә ияреп: «Әүвәл Аллага, икенче сиңа тапшырдым», – дип, ул хәзрәтне Аллаһ Тәгаләгә тиңдәшлек итмәсләр һәм, баланың тиресе белән сөяге миңа, ите сиңа, дип уртакка асрамага биргән са-

рык бәтие кебек итеп, сабак укыйсы баланың котын очырмаслар, Аллага тапшырдым, дип кенә сүзне тәмамларлар. Баласы сабакны укый башлагач, кайсы сәгатьтә сабакка барасы, кайсы сәгатьтә мәктәптән кайтасы вакытларын хәлфәләрдән сорап белешерләр. Баланың кайтуына, аш әзерләп куясы урынга, эш әзерләп куелса, ул баланың укуда ихласлыгы булмаячагы мәгълүм. Ашарга әзерләп, башка эшкә кушмыйча, барасы сәгате җиткәч, кичектерми җибәрерләр һәм хәлфә баламны укыта дип, үзләре тыныч ятмаслар, бәлки хәлфәдән даими белешеп торырлар: бала сабагына вакытында барамы, сабак укыган вакытында уйнап утырмыймы, барганда-кайтканда уйнап, сугышып йөрмиме – барысын да тикшерерләр һәм пәнҗешәмбе сәдакасын атасы биргәнчә хәлфәсенә илтеп бирәме яки акчасының беразына юлда perәннек яки хәлвә кебек нәрсәләр ашап, хәлфәгә калганын гына илтеп биреп кенә йөрмиме – шуларның барысын да хәлфәдән белешерләр. Бу оят эш түгел, бик кирәкле эш.

Тәрбияле аталар баланың уку кирәген тоткарламыйча алып бирерләр, китап, кәгазь, карандаш, каләм, кара кебек нәрсәләрне тоткарламаслар, «Хәзер генә алып биргән идем, кайда куйдың», – дип баланы орышып, кулын бәйләгән кебек, язудан һәм сабактан ихласлыгын чыгармаслар. Тәрбияле аталар хәлфәгә пәнҗешәмбе сәдакасын бик аз да бирмәсләр, хәлфәләрнең балаларына никадәр хезмәте кергәнен белерләр. Үзләре бер кешегә көн саен утын ярсалар яки әвен суксалар, ничә тиен алырга риза булырлар иде – шуннан үлчәп, хәлфәләргә хак [акча] бирерләр. Хәлфәләр Аллаһ ризалыгы өчен укыталар, дип белеп, пәнҗешәмбе көн өч тиен, биш тиен биреп, хәлфәләрнең бала укытуда булган ихласлыгын

сүндермәсләр. Үзеннән хисаплап һәм хәлфә дә үзе шикелле кеше, фәрештә түгел, ашау-эчүе, өс-башы бар, дип, хәлфәнең баласына күпме хезмәте кергәнен уйлап, хәле җиткәне егерме тиен яки ун тиен бирер, бирә алмастайларыннан хәлфә дә өмет итмәс. Уку рәвешен карар, балада белү куәте һәм уку дәрте була торып, хәлфә тарафыннан укытуда җитешсезлек беленсә, хәлфәсеннән чынлабрак укытуын үтенер. Һәрвакыт баласының газиз вакыты бушка үтмәвен, надан калып, дөнья һәм ахирәте харап булмавын исендә торырлар.

## Ир балалар тәрбиясе

Балаларның яшь вакытындагы тәрбия рәвешен язып узган идек. Монысы исә уналтыдан үткән ир балалар тәрбиясе турындагы сүзләр.

Хакыйкатьтә, аталарның башны ваткан, зиһенне чуалткан, рәхәтлекне җибәргән иң авыр мәсьәлә дә – бу. Бу турыда күп ата ялгышуда: үзенең шундый яшь вакытын искә төшереп, үзеннән өлге кисеп, баласына киертүдә (балага явыз ният кылып түгел). Моның белән күп үсмерләребез эштән чыгуда.

Балага: «Мин синең күк чакта этигә шулай булдым, болай булдым, син дә шулай эшлә», – дип, үзеннән бер дә фикер сорамыйча, көчләп бер эшкә кушса, ул эштән бәрәкәт чыкмавы өстенә, бала да юктан чыга (көчләп өйләндерү, яратмаган кызын алып бирү дә шул җөмләдән). Менә ир баланы кече яшьтән сынап килергә тиеш. Аның бер дәрт иткән нәрсәсе була. Шуны хәтерләп, шуңа карабрак, үзеннән дә: «Кайсын ихтыяр итәсең», – дип сорарга тиеш. Бер

сәүдәгәрнең улы сәүдәне сөйми, иген игүне ярата яки бер мулланың улы мулла булырга теләми, сәүдәгәр буласы килә. Шулай ук иген игүченең улы укымакчы була, шуның аркасында мулла буласы килә. Менә мондый эшләрдә баланың теләгәне мөмкин була торган булса, үз ихтыярына салырга кирәк. Көчләп кушылган сәүдәгәрлектән һәм ирексезләп ителгән муллалыктан бәрәкәт чыкмавы мәгълүм булган мәсьәлә. Әгәр мөмкин булмый торганны теләсә, кимендә, аның сораганы шул җәһәттән мөмкин булмаганын төшендереп, нәсыйхәт биреп, күндерергә кирәк һәм үзе теләгән эшне биргәндә дә, тыныч тормаска кирәк, эшне яхшы алып барамы, ялкаулык кылмыймы, ун тиен тотасы урынга егерме тиен тотмыймы – һәркайсын күзәтеп һәм шундый кешеләрдән гыйбрәтләр, мисаллар сөйләп, нәсыйхәт бирә торырга кирәк. Балаларының бер ярамаган эшне күрсәләр, яшь чакта аз гына булмый хәле юк, дип күз йомып калмаслар, бу хакта үзләренең зур кайгыга төшкәнлеген белдереп, бик каты нәсыйхәт бирерләр. Кайбер аталар, үзләре яшь вакытында ярамас эшләрдә булган булсалар да, балаларына һәм башкаларга һич белдертмәсләр. Гүя үзе ул сыйфатта бер дә булмаган төсле булып, балаларына әдәп, замандашларына нәсыйхәт бирерләр. Балаларына җәза биргәндә, аналары аркылы төшсә, бу турыда арасына кермә, дип, аналарына зур гайрәт күрсәтерләр. Әгәр бер ата бала үстергәндә, үзе яман эштә булса яки яшь вакыттагысы белән мактанып йөрсә, баласының яхшы булуын өмет итмәсен, баласына җәза да биреп маташмасын. Тәрбияле аталар, башта үзе яшь вакытындагы яман хәлләрен кешегә белдереп, үрнәк булуыннан куркырлар. Үзе яшь вакытындагы гадәтен ташлаган

булса да, икенче яшьләрнең яшь вакытындагы гадәтләрен ташлый алмыйча гомерләрен хараплыкта үткәргәннәрен күреп, яшь уллары өчен бигрәк тә кайгырырлар.

Тәрбияле аталар балаларына әби-бабаларын, ир һәм кыз туганнарын, нәсел-нәсәпләрен әйтеп, белдерергә тиеш. Ата гомерендә йөрешелмәгән якын карендәшләр[5] бала гомерендә ят кеше хөкеменә кереп китмәсен. Аларга файда тидерү яки алардан файда күрү мөмкин булганлыктан, аларны белеп торырга кирәк.

## Кыз балалар тәрбиясе

Кыз-балаларга язу өйрәнү кирәкмәс, язу белсә, егетләргә хат язарлар, дип язудан тыймаслар. Бәлки кызларының кияүгә барганнан соң, иренә хат язу булганда, һичкемгә әйтергә ярамый торган мәхәббәт йөзеннән килгән сүзләрен бер ят кешегә әйтеп яздырып, серне фаш кылуын лаек күрмичә, мөмкин кадәр язуга өйрәтергә бигрәк тырышырлар. Пәйгамбәребезнең (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) «Гыйлем алу һәр мөселман иргә һәм хатын-кызга мәҗбүри» дигән сүзләренә игътибар итәрләр. Язу язган ир һәм хатыннарның өйрәнгән гыйлемнәре әрәм булмас. Кул эшләрен, аш пешерү гыйлемен өйрәтергә акчалар тотып тырышырлар.

[5] Ихтимал, атасы фәкыйрьлек белән йөрешмәгән булыр.

## Үсмер кызларның тәрбиясе

Кыз баланың ят кеше кулына барып төшкән вакытында, эш белми гаҗиз калып, кайната аналар тарафыннан, киленнән уңмадык, дигән сүзләрне кызы өстенә сөйләнүне баштан ук уйлап, ир балага караганда да яхшырак әдәп бирдерергә тырышырлар. Кызлары кайнеш йортына төшеп, бер-ике ел торыр-тормыйча да, кайната-кайнана белән бозылышып, без болардан башка тора белмибезмени, дип, кияүне котыртып, башка чыгарга киңәш бирмәс өчен, каената, каенана, каенага, каенигәч, килен-килендәш белән бозылышмый бергә гомер итүгә нинди үгет-нәсыйхәтләр кирәк – барысын да эшләрләр. Тәрбиясез ата-ана кулында үскән яшь киленнәр йортка килү белән, зур исем исемләнгән бер йорт җәмәгате бозылышып, төрлесе төрле урынга башка чыгып, утлы күмер кебек сүнеп бетәләр. Шуның өчен дә борынгылар: «Хатыннар бозык булмаса, йорт эче төзек була», – дигәннәр. Бу – бик хикмәтле сүз.

Тәрбияле аталар кызын кияүгә биргәч тә, тынычлап, рәхәт булып тормаслар, бәлки кызының рәхәт гомер кичерүе өчен кирәкле булган хәлләрне кайгыртырлар.

Аеруча кызының кияү белән яңа башлаган тормышлары ни рәвешле бара, араларында сүз тудырачак бер нәрсә юкмы, шулай ук йортның олылары булса, аларга кызы илтифатсыз түгелме, аз нәрсәгә күңелләре булып, шатланачак олыларга тәкәбберлек һәм горурлык кылып йөрмиме – боларның һәркайсын сорашып белергә мөмкин эш. Әгәр кызы тарафыннан кимчелек барлыгы беленсә, кызын бик каты үгет-нәсыйхәт бирерләр.

## Кыз бирү

Безнең ата-аналарыбызның кыз бирүдә булган кимчелекләре санап бетергесез булып, беренчесе – кызларын бик яшьли бирүләре. Бичара кыз бала дөньяда һич рәхәт күрми кала. Ничек күрсен, ул сигез-ун яшьләренә җиткәч, унбишкәчә уку белән мәшгуль була. Буш һәм хуш сәгате булмый. Ничек уналтыга җитте исә, суларга да ирек бирмичә, кияүгә бирәләр. Йорт итүне, бала тәрбияләүне, икътисад җәһәтләрен, өй эшен күрмәгән һәм белмәгән хәлдә кияүгә барып, бала да китерә башлап, йорт эше, ир хезмәте, бала мәшәкать һәм борчулары муенына йөкләнсә, бичара яшь җан күтәрә алуыннан гаҗиз кала. Шуның белән күбесе башбөтен өстенә йөкләнгәннәрнең берсен дә үти алмый, зиһене томалана, дөньяга килгәненә үкенә башлый, авыруга сабышып үләләр дә. Икенче сәбәп – ул кызның ата-анасы күп елгача юлдаш булачак кияүнең кызына каршы табигатьтә булу-булмавын һич тикшерми. Мәсәлән, кызы галимә, укуны сөючән булып, укуның дошманы булган бай мужик улына бирелсә; кыз бик пакизә булып, бик кара бай улына бирелсә; кызы юмарт, фәкыйрьләргә яхшылык итүне сөюче булып, бик саран бәхилгә бирелсә; кыз йомшак күңелле, мөлаем табигатьле, кешеләрне кызганучы булып, тәкәббер, үзеннән башка беркемне дә һич кызганмый, тик үз файдасын гына күзли торган байгурага бирелсә; кыз яшь булып, кырык-илле яшьлек, гомернең ахыргы бүлмәсенә кергән картка бирелсә; бу әйткәннәрнең арасында ничек өлфәт, тынычлык, сөекле ләззәтле тормыш була алсын. Мондый рәвештә бирелгән кызларның йөрәкләрен чиксез булган хәсрәт яндыруда. Ул

хәсрәт башка хәсрәтләр кебек кешегә сөйләп, эчне бушата торган хәсрәт булмыйча, йөзенә салкынлык һәм чырайсызлык, күңеленә тарлык, ачу, шомлык, бозык кан белән тәмсез, ләззәтсез тормыш итүгә сәбәп була.

**Нәтиҗә.** Бер хатын шушы сыйфатта булган хәлдә, кайсы ир шат булып яши белер? Димәк, болар һәр икесе дә югарыда дигәнчә булалар. Шулай булгач, боларның суыннан яралып, болардан туган балалар да кемгә охшап ачык чырайлы, якты йөзле булып тусыннар? Бер кешенең кызы яки улы матур булса, аның анасы бик матур шул, дип әйтәбез бит. Аның өстенә туган балаларыбызны тәрбияләүдә хисапсыз кимчелекләребезне өстәсәң, хәйран калырлык эшләребез бар.

Үсүдә булган балаларның шат булулары өчен гөнаһ та, савап та булмый торган уеннарда ирек биреп, хәтта үзебез уйнатасы урында, кит моннан, уйнама, монда чүпләмә, кая карасаң, синең чүбең, дип, көн саен ачулану; баланың киләчәктә сүз төзүгә куәте булсын өчен, үзебез берәр кыска җөмләле сүзне сорап, аннан да әйттереп, әйтә алмаганын үзебез булышып, сүзен тәмам иттереп сөйләшергә өйрәтер чакта, бала бер нәрсә хакында сорашмакчы булса яки бер нәрсәне үзе сөйли башласа, зур булгач, барын да белерсең, тик тор, олылар барында сөйләшмә, дип туктатуларыбыз белән һәм зурайгачрак күрсәтә торган гайрәтебезне вакытсыз кулланып, баланы каты куркытабыз. Бичара балаларның тәмам һава алып сулаган сулышларының күбрәгендә курку һәм йөрәксезлек астында булулары табигатькә нык күчеп, бу да караңгы чырайлы булырга икенче мәртәбә сәбәп булуда. Ник соң балаларыбызга ачуланабыз икән, дип, сәбәпләрен эзләмәкче булсак, әлеге ир белән хатынның араларында эз-

лекле хуш тормыш булмавы – зур сәбәп. Чөнки һәрдаим бер борчу эчендә нервный авыруга дучар булып, аз нәрсәгә дә ачуланучан була.

## Угыл өйләндерү

Угыл өйләндерүдә булган кимчелекләребез дә кыз бирүдә булган кимчелеклекләребездән ким түгел. Угылларыбызның үзләре белән киңәшләшмичә, табигатенә башка, бүтән, каршы булган бер кызны алып биреп, күп зарар кылуда без. Угылларыбызның теләмәгән кызларын алып бирүебез сәбәпле, ике хәлнең берсенә очраулары тиешле булып, кимендә, берсеннән котыла алмаулары мәгълүм. Бу хәлдә, үзенең киңәшеннән башка алынган килен аңа ошамаса, угыл үзендә булган ихтыярдан файдаланып, аны аерырга, икенчене алырга мәҗбүр була. Берне аласы урынга ике мәртәбә туй ясап, кабат чыгымнар кирәк була. Аннан башка, угылның төрле хатыннан файдалану, ләззәтләндерүгә юлны ачып тагын ничәләрне алып, аерырга, ничә кызның тол ятим калуларына сәбәп була. Икенче хәлдә исә, угылның өйдән бизеп, өйдә җәмәгате янында үткәрәсе сәгатьләрен башка ярамаган йортында үткәрүенә, шуның белән эшеннән, малыннан, кәсебеннән дә аерылып, һәлак булуына сәбәп була.

## Үсмер улларыбызның тәрбиясе

Улларыбызның тәрбиясе кызларныкына караганда мөһим булган кебек, яшь вакытларына караганда, зурайгач булган хәл һәм сыйфатлары бөтенләй башка. Улларыбыз зурай-

гач һәм укыгач, һәркайсы диярлек үзен атасыннан белемлерәк күреп, эшендә мөстәкыйльлекне сөеп, һавасына кол булырга, ягъни нәфесенә генә итагать итүгә, нәфесе кушканны атасы кушканнан беренчерәк үтәүне сөюдә. Шуның белән бргә, үзе баш булса, башка төрле эш күрер төсле булып, атасының эшен тәнкыйтьләүдә. Әнә ата булган кешегә тотсаң – пешерүдә, ташласаң – сүнүдә булган утлы күмерне кулга тотып тору белән бәрабәр.

Һәм дә өйләнү, зөфаф кичәсендә кунак булу, балалар булып, аларны сөеп, рәхәтләнү, әби-бабасы белән кунакка йөрешү кебек узган рәхәтлкләренең барысын да җуя торган көн дә – бу көн. Бу вакытта бәхетле аталар салкын кан белән чыдап, эшләрнең җайланып китүен дә булдыра алалар. Кайберләре электән килгән башлык, мөстәкыйльлек, үзембеләмлек белән ничә еллардан бирле күзәтеп килгән өметләреннән мәхрүм дә калалар. Уллар белән каршы килгән мәсьәлә турында сүзне, әмерне кырт кисү, мөстәкыйльлекне үтәү аларга бик каты килә. Нигездә, дөньяда гәүдәсе булмый торып, ямьсез күренгән нәрсә булса, ул да – мөстәкыйльлек. Аталар бу мөстәкыйльлекне ташлап, кулыннан килердәй эшләрне аларга тапшырып һәм дә аларны тикшерүсез куймасалар, ул улларның тугры юлга төшүләре өметле. Аллаһ үзе хәерлегә күндерсен.

## Ир балалар белән өлфәт

Адәм баласына туганнары, якыннары белән кардәшлек һәм туганлыкны суытмый тору никадәр мәҗбүри булса, алардан ничә йөз мәртәбә үзенең балалары белән өлфәт һәм

мәхәббәтчә яшәргә тырышырга кирәк. Балалар тәмам ышансыннар ки, син аны камил сөясең, ләкин, сөям, дигәч тә, ул ни эшләмәкче булса, шуның барысына да ирек бирү белән түгел. Аннан соң үзең аннан тәрбия күрсәң һәм аның тәрбиясенә мохтаҗ икәнеңне даими колагына төшереп, аның бәрабәренә аңа дога кылачагыңны, хәер-дога алган балаларның дөньяда, ахирәттә бәхетле булачакларын сөйләргә кирәк.

Әгәр бер ата үзен тәрбия җәһәтендә дә баласына кабат нәсыйхәте булмаган булса, ул ата баласына үпкәләмәсен. Тәрбияләүчене күрмәгән, тәрбияләү юлын һичкемнән өйрәнмәгән бер бала ата-анасының тәрбиясе хакында кимчелек ясавы шөбһәсез. Безнең ата-аналарыбыз күп вакытта, баласы җиткәнче, баласыннан биш тиен булсын, акча сорап алмаган була.

Үзеннән башка җирдән килүе булып, улымны борчымыйм, дип, яхшылык итмәкче була. Кинәт үзенең килер җире тукталып, баласыннан сорый башласа да, әлеге бар акчасын үзенә генә тотып өйрәткән балага атасына акча чыгарып бирү бик авыр була. Күбесенчә, балалар инкяр дә итүче булып гөнаһлы да була. Әнә шушы юлга җибәрмәсен өчен, улының кәсебеннән килгән хәләл акчасыннан, кирәк булмаса да, үзенә өлеш сорап ала килеп, аздан гадәтләндерү кирәк. Баланың кулы атасына биреп өйрәнсен. Баласы читтә булса даими хат язсын. Ул да язмый, мин дә язмыйм, дип торса, баласын югалттым, дип хисапласын. Азмы-күпме вазыйфа [хезмәт хакы] алып торса, аз алган чакта ук үзенә бер өлеш сорап алсын. Бер угыл 50 сум вазыйфа алганда, атасына биш сум биреп өйрәнмәсә, 500 сум ала башлагач, 50 сум бирергә нәфесен җиңә алмас. Бу – тәҗрибә белән беленгән эш.

Бу исә улын яхшы эзгә бастыруның бик зур шартларыннан. Шушы эз белән балалар бәхет юлына керәләр.

## Хатыннарын кунакка җибәрү рәвеше

Тәрбияле ирләр үзләре белән бергә гомер итүдә булган, яхшылыгы белән сыналган хатынны йорт эченә баш итәрләр. Аны кимсетү, орышу, кыйнау яки, өстеңнән яшь хатын алам, дип ярсытулар, йортымда бәрәкәт булса иде, дигән иргә һич ярый торган эш түгел. Чакырган бер җиргә кунакка җибәрмәсәләр дә, җибәрүе мөмкин булган урыннарга чыгармый, ябып та асрамаслар.

Ләкин барганда, иң олы киемнәрен киеп, кершән ягынып, урамда очраган ирләрнең күзләре төшеп, ай, бу хатын миңа булсачы, дип кызыгырлык рәвештә барырга кушмаслар. Бәлки матур киемнәренең өстеннән гадәтчә генә җилән яки шәл бөркәнеп, барырга әмер итәрләр. Әгәр ат белән барачак булса, арба турына ялгыз утыртып, кучер белән генә җибәрмәсләр. Янына асрау яки бер бала утыртырлар.

## Хатыннарның кунак чакыру рәвеше

Хатыннар, үзләре кунак җыймакчы булсалар, тиешле булган хатыннарны гына чакырырга әмер итәрләр. Аш-суны да кыланусыз итәргә кушарлар. Тәрбияле ирләр, хатыннары кунак чакырган көнне ничә вакыт намазны калдырып, бөтен көнне әрәм иттермәсләр. Тиз җыелып, тиз таралырга әмер итәрләр.

## Хатыннарга кием ясау рәвеше

Тәрбияле ирләр хатыннарын үз милләтебезгә охшашлы киемнәр белән киенергә әмер итәрләр. 50 сумлык кием җитәсе урынга, 200 сумлык кием ябындырмаслар. Хатыннары күлмәклек сорасалар, урыны белән кия торган биш-алты күлмәгеннән башка, сандыгында ун-унбиш күлмәге булуыннан хәбәрләре булыр. Бәлки үзенең кәсебеннән килгән файда ни рәвешле булачагын хисапламыйча, бирәчәген хисаплап, кулындагы малына чамалап, чыгым тотарлар.

## Хатыннарын урамга чыгару рәвеше

Тәрбияле ирләр хатыннарын урамга гозерсез чыгармаслар. Тиешле урынга барачак булса, йөзләрен чит ирләрдән яшереп йөрергә әмер итәрләр. Таган асты һәм Сабан туе кебек ирләр җыелган җиргә чыгарга һич рөхсәт итмәсләр.

## Ирләрнең үзләренә кием рәвеше

Тәрбияле ирләр үзләренең кәсебе рәвешенә карап, кием ясарлар. Урыны белән, яхшы киемнәрне киярләр. Кәсебе уртача булып, яхшы киемнәр кияргә хәле җитмәсә, булганча керсез һәм пакъ итеп киярләр. Тәрбияле ирләр кәсепләренең алга китүенә тырышырлар. Бишвакыт намазларын һич калдырмаслар, намаз калдырмаган сатучының кәсебендә бәрәкәт булыр. Чәйханәләргә кереп яки урам почмакларында төрле кешеләр белән суган сатып, вакыт үткәрмәсләр. Бәлки сәүдәләре сәбәпле, күрергә тиешле булган кешеләр белән яки

үзенә нәсыйхәт һәм киңәш бирә торган кешеләр белән генә утырышып, башка вакытларын кәсепләренең өстендә кичереп, кич кайтыр вакытында җәмәгать һәм балаларын зарыктырмыйча, өйләренә кайтып, хатын һәм балаларының хәтерләрен табарлар.

## Галимнәргә ихласлык рәвеше

Тәрбияле ирләр үзенең мәхәлләсендә булган бер мулласын гына яратып яки баласына остаз булган бер хәлфәне генә сөеп, башкаларына ихласлык утыртмыйча, кая безнең фәлән хәзрәткә җитәргә, дип, мулла һәм хәлфәләргә номер сукмаслар, бәлки кайсыдыр мулла мәчетләрдә, мәҗлесләрдә үз кардәшләребезне вәгазь итүче булганлыктан, кайберсе мөселман кардәшләребезнең балаларына дин өйрәтеп, хезмәт кылганлыктан, теләсә аның мәхәлләсендә булсын, теләсә булмасын, теләсә баласының остазы булсын, теләсә булмасын – барысын да сөярләр, тел озайтмаслар.

## Тәрбияле ирләрнең сүз сөйләү рәвеше

Тәрбияле ирләр сүзне үлчәп сөйләрләр. Мәсәлән, бер мәҗлестә үзеннән артык белүче кеше булмаса, әдәп белән генә сөйләшерләр. Кешеләргә нәсыйхәт бирерләр, бер кеше хакында бер адәмнән бер сүз ишетсә, ышанып бетеп, кабынып китмәсләр. Ул кешедән андый эш булырга охшыймы – әүвәл шунысын бик яхшы уйларлар. Әгәр ул кешенең ул эшне эшләве мөмкин булса, Аллаһ тәүфыйк бирсен, диярләр. Әгәр хак булырга охшамаса, яла ягу булмаса иде, дип

сөйләүчеләрне тыярлар. Күзе белән күреп, колагы белән ишетмәгән эшкә ышанмый калу гөнаһ эш түгел, бәлки савап эш. Кыскасы, шул һәр кешедән ишетелгән сүзнең барысы да дөрес дип белеп, барысына да ышанмаслар. Шәригатьтә дөрес булган эшне, гадәткә каршы булса да, кабул итәрләр. Шәригатьтә хәрам булган эшне, гадәткә караганда, дөрес булса да, эшләмәсләр. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә барчабызга тәрбияле ата булырга насыйп итсен! Амин!

**Кадим бишегеннән ишетелгән моңлы шигырь**

Әлли-әлли итәр бу, тыныч йоклап китәр бу.
Шулай тыныч йокласа, бик тиз үсеп җитәр бу.
Үскәч, сабак укыр бу, абыстайдан куркыр бу.
Ата-анасы кулында сәгадәткә йолкыр бу.
Иҗек укып йөрер бу, «Кисекбаш»ны белер бу.
Бер күтәрәм күләмендә сабак тотып йөрер бу.
Абыстасы бик мактар, бу башкаларны таптар.
Ысул җәдид ярамый, дип, ысул кадимне мактар.
Абыстасы яратыр, исемен илгә таратыр.
Өйләнмәгән яшь егетләр бер күрергә җан атар.
Моңа яучылар килер, әнкәсе: «Бирмим», – дияр,
«Ысул кадим булса ярый, җәдидне сөймим», – дияр.
«Мәгъшукнамә» дә алыр, тешенә сөрмә салыр.
Күрше авылда апасына утырмага да барыр.
Иннек, кершән ябыныр, чәч тәңкәсе тагылыр.
Хак бәндәсе так яралмый, үзенә тиң табылыр.
Анда булыр, күп эшләр, йокыда күрер төшләр,
Шулай итеп бу кызга зәвыклы булыр кичләр.

## Милләтнең барышына бер караш

Әй, күрексез, әй, кадерсез, әй, белексез милләтем.
Әйтсәнә, син, тел яшермә, кайда синең гыйлләтең [чирең]?
Синдә булса бер мөгаллим – күп яшәми, ул үлә.
Синдә булса бер юмарт бай – күпкә бармый, ул бөлә.
Синдә булса бер саран бай – йөзгә җитсә дә җитә.
Синдә булса чын зыялы – ярты гомерендә китә.
Синдә булса бер мөдәррис – дошманыннан үрелә.
Озак та тормый ул мөдәррис, кая булса сөрелә.
Талпынабыз, талпынабыз, алга барып булмыйдыр,
Эшебезнең бересе дә уйлаганча булмыйдыр.
Әй, бәхетсез, әй, тәхетсез, иттифаксыз милләтем.
Синдә инсан, синдә ихсан, кайда синең гыйззәтең?
Нигә болай, нигә соң бу барысы да кире килә?
Күпме качсак иске тормыш ул һаман бире килә?
Көтмә гыйззәт, көтмә хөрмәт, синдә гыйлем булмыйча,
Сайрый торган бер матур кош баш түбәңә кунмыйча.

**«Ибраһим».**

Составители:
***Гайнутдинов Айдар Марсилевич***
***Низамиев Ильнур Ильдарович***

***Идрис Ибрагимов***

**Благонравный отец или урок жизни**
*(на татарском языке)*

*Научно-популярное издание*

Оригинал-макет – *Л.М. Зигангареева*
Подписано в печать 21.10.2019 г. Формат 60×84 $^{1}/_{16}$
Усл. печ. листов 2,0  Тираж 300 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета

ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ
*им. академика В.И. Андреева*

420108, г. Казань, ул. Портовая, 25а
Тел./факс: (843) 231-05-46,
231-08-71, 231-04-19
E-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru